**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Кәрәкәшле торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

11 ноябрь 2024 ел № 10

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Кәрәкәшле торак пункты территориясендә 2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның якын туганнарыннан (ата-аналарыннан, тормыш иптәшләреннән), Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылганнар гражданнардан тыш, 500 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга (Кәрәкәшле торак пунктында юлларны кардан чистарту (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Кәрәкәшле торак пунктындагы чишмәне төзекләндерүгә (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));;
- халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү (паркларны, скверларны, яр буйларын, пляжларны, спорт мәйданчыкларын һәм халыкның күпләп ял итү өчен бүтән урыннарны) һәм аларга якын территорияне төзекләндерүгә (Кәрәкәшле торак пунктында балалар өчен уен мәйданчыгын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү));
- Кәрәкәшле торак пунктында күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау (зират территориясен киртәләүгә (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Кәрәкәшле торак пунктында күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, койма белән әйләндереп алуга (чүп үләннәрен юкка чыгару, корыган агачларны, куакларны кисү (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) юлларга.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында элəргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев